КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 30 декабрь г.Казань № 1135

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Эш бирүчегә һөнәр белеме бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча вакытлыча эшкә урнаштырылган эшсез гражданнарга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү тәртибен раслау турында” 2014 ел, 28 февраль, 128 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Эш бирүчегә һөнәр белеме бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча вакытлыча эшкә урнаштырылган эшсез гражданнарга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү тәртибен раслау турында” 2014 ел, 28 февраль, 128 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Эш бирүчегә һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча вакытлыча эшкә урнаштырылган эш белән мәшгуль булмаган гражданнарга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен кайтаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында”;

преамбулада “эшсез” сүзен “эш белән мәшгуль булмаган” сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Карарга теркәлгән Эш бирүчегә һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча вакытлыча эшкә урнаштырылган эш белән мәшгуль булмаган гражданнарга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен кайтаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.”;

әлеге карар белән расланган Эш бирүчегә һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча вакытлыча эшкә урнаштырылган эшсез гражданнарга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин